**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 14 сентябре** **№ 88**

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 15 июнендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында”гы 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы Федераль законының 15 маддәсенә үзгәреш кертү турында”гы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2017 елның 15 июнендәге 49 номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган, “Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

Кагыйдәләрнең 85.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“85.8. туктап тору территориясенә инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү. Транспорт чараларының һәр туктау урынында, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, I, II төркем, шулай ук III төркем инвалидлар йөртә торган транспорт чараларын һәм шундый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен 10 проценттан ким булмаган (әмма кимендә бер урын) урын бүлеп бирелә. Күрсәтелгән урыннарны парковкалау өчен башка транспорт чаралары биләргә тиеш түгел.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Красноармейская ур., авыл үзәге;

- ТР, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Колхоз ур., йорт 16а, китапханә бинасы;

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан РеспубликасыКама Тамагы
муниципаль районы Сөйки
авыл җирлеге Советы рәисе В.П. Никитин